КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 9 апрель г.Казань № 215

2018 елда Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында

Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән саклык чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 ел, 25 апрель, 390 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елның 25 апреленнән Татарстан Республикасы территориясендә янгын куркынычы сезоны башлана дип билгеләргә.

2. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

урманнардагы янгыннар куркынычы яный торган Татарстан Республикасы торак пунктлары исемлеген;

гражданнарның Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, урман кишәрлекләре белән чиктәш булган коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре исемлеген;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, урман кишәрлекләре белән чиктәш булган балалар ялын һәм аларны савыктыруны оештыручы (шул исәптән балалар көндез була торган) оешмалар исемлеген;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, урман кишәрлекләре белән чиктәш булган икътисад объектлары исемлеген;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, урман кишәрлекләре белән чиктәш булган савыктыру оешмалары исемлеген.

3. Тәкъдим итәргә:

территорияләрендә урманнардагы янгыннар куркынычы яный торган торак пунктлары урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләренә янгын куркынычы сезоны башланганчы:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 ел, 25 апрель, 390 нчы карары белән расланган Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренең XX бүлеге нигезендә үз вәкаләтләре кысаларында урманнардагы янгыннар куркынычы яный торган торак пунктларын паспортлаштыруны тәэмин итәргә;

түбәндәгеләр буенча чаралар башкарырга:

урман массивлары буйлап минераллаштырылган саклау полосаларын булдыру;

торак пунктларны телефон элемтәсе һәм янгын турында тавыш белән хәбәр итү чаралары белән тәэмин итү;

янгын сүндерү максатларында су чыганакларын җиһазлау;

янгынга каршы ирекле формированиеләр әгъзапларының тәүлек әйләнәсе кизү торуын оештыру;

Татарстан Республикасы территоиясендә урнашкан урман кишгәрлекләре белән чиктәш гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре рәисләренә, балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерүне (шул исәптән балалар көндез булу белән) оештыручы оешмалар, икътисад объектлары һәм сәламәтләндерү оешмалары җитәкчеләренә янгын куркынычы сезоны чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча кирәкле чаралар күрергә.

4. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына урманнардагы янгыннар куркынычы яный торган торак пунктларын паспортлаштыруда җирле үзидарә органнарына методик һәм гамәли ярдәм күрсәтергә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында» 2014 ел, 12 апрель, 236 нчы;

«Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында» 2014 ел, 12 апрель, 236 нчы карары белән расланган урманнардагы янгыннар куркынычы яный торган Татарстан Республикасы торак пунктлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 27 май, 356 нчы;

«Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар турында» 2014 ел, 12 апрель, 236 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 24 март, 163 нче.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин